**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ЛАИШЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**

Чернышевского ул., д.23, г.Лаишево 422610

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЛАЕШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

Чернышевский урамы, 23 нче йорт Лаеш ш. 422610

Тел: 8-(84378) -2-52-28 Факс: 8-(84378) -2-54-34

e-mail: Ispolkom.Laishevo@tatar.ru

2022 елның 10 августы 1848 номер

# КАРАР

## «Пелево Престиж»коттедж поселогы территориясен планлаштыру һәм ызанлау проектын раслау турында

Территориянең тотрыклы үсешен тәэмин итү, планлаштыру структурасы элементларын (кварталлар, микрорайоннар, башка элементлар) бүлеп бирү, капиталь төзелеш объектлары урнашкан җир кишәрлекләре чикләрен, линияле объектлар төзү һәм урнаштыру өчен билгеләнгән җир кишәрлекләре чикләрен билгеләү максатларында, Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 42, 45, 46 статьялары, «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Уставына таянып, 2021 елның 3 ноябрендә үткәрелгән ачык тыңлаулар нигезендә КАРАР ИТӘМ:

1. «Пелево Престиж» коттедж бистәсе территориясен планлаштыру һәм межалау проектын расларга (кадастр номерлары 16:24:030201:132; 16:24:030201:133; 16:24:030201:134; 16:24:030201:135; 16:24:030201:136; 16:24:030201:137; 16:24:030201:138; 16:24:030201:139; 16:24:030201:140; 16:24:030201:141; 16:24:030201:142; 16:24:030201:143 булган җир кишәрлекләре).
2. Әлеге карарны “Кама ягы”(«Камская новь») район газетасында, Интернет телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru. веб–адресы буенча һәм интернет телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре Порталында урнаштырылган Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының рәсми сайтында- http://laishevo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча бастырып чыгарырга (халыкка җиткерер.
3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемдә калдырам.

Җитәкче вазыйфаларын
башкаручы А.Г.Карсалов